РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» 05 2019 г. №351

“Дәүләти һәм муниципаль

хезмәтләр Исемлеген раслау

турында”

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган теркәлгән дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр Исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге турында”гы 2012 елның 26 июнендәге 467 санлы карарын;

- 2018 елның 28 маендагы “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында»гы №19 карарын;

- 2014 елның 19 ноябрендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында " № 47 карарын;

- 2015 елдагы «Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында”гы №4 карарын;

- 2014 елның 19 ноябрендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында " № 47 карарын;

- 2011 елның 31 гыйнварындагы «Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" № 113 карарын;

- 2018 елның 18 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы архив бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» №419 карарын;

- 2018 елның 18 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы архив бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» №420 карарын;

- 2018 елның 4 маендагы «Торак өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» №276 карарнын;

- 2018 елның 28 маендагы «Ютазы муниципаль районы җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасының муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" №366 карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Оештыру бүлегенә өч эш көне эчендә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

М.В. Ларин

2-74-11

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды

_______ ел № ______

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелгән дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр Исемлеге

*Дәүләти хезмәтләр*

1.Өлкәннәрне Психоневрология тибындагы интернат-йортларга стационар хезмәт күрсәтүгә җибәрү турында карарлар бирү.

2. Суд тәртибендә эшкә сәләтсез яки чикләнгән сәләтле дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү.

3. Опекага алынучы мәнфәгатьләрендә гомерлеккә рента килешүе төзүгә рөхсәт.

4. Опекунга эшкә яраксыз балигъ булган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү.

5. Опекунга үз опекасындагы баланыкы булган торакны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү.

6. Карамактагыларның милке белән алыш-биреш ясау өчен рөхсәт бирү.

7. Опекунга опекага алынучының яшәү урыны үзгәрү сәбәпле, опекунга аның карамагындагы затны яшәү урыны буенча теркәү учетыннан төшерүгә рөхсәт бирү.

8. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен рөхсәт бирү.

9. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счеты белән файдалануга рөхсәт бирү.

10. Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булмаган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.

11. Балигъ булмаганнар (алар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү.

12. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак исәпкә кую.

13. Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга алдан рөхсәт бирү.

14. Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү.

15. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.

16. Эмансипация турында карар кабул итү (балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү).

17. Балигъ булмаган балага караган күчемсез милекне читләштерү буенча алыш-бирешләргә алдан рөхсәт бирү.

18. Кредит акчаларын кулланып торак сатып алуга һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залог (ипотека) итеп тапшыруга башлангыч рөхсәт бирү.

19. Законлы вәкилгә балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга рөхсәт бирү.

Социаль учреждениедә стационар хезмәт күрсәтүгә сәләтсез дип танылган балигъ булмаган затны РФ территориясендә даими яшәүче гражданнарның гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында бәяләмә бирү.

Баланы (балаларны) опекунга яки попечительгә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга акча билгеләү һәм түләү, шулай ук опекуннарга яки үз-үзен тотучыларга тиешле түләү.

20. Бала тууны дәүләт теркәвенә алу.

21. Никахны теркәүне дәүләт теркәвенә алу.

22. Аерылышуны дәүләт теркәвенә алу.

23. Уллыкка (кызлыкка) алуны дәүләт теркәве.

24. Атаны билгеләүне дәүләт теркәвенә алу.

25. Исемне алыштыруны дәүләт теркәве.

26. Үлемне дәүләти теркәү.

27. Граждан хәле актына үзгәрешләр кертү

28. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкларны һәм гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактын раслаучы башка документларны (белешмәләрне) кабат бирү.

29. Гражданлык хәле актларын теркәү (гамәлдән чыгару).

30. Дәүләт милкенә кертелгән архив документларының урнашу мәсьәләләре буенча консультация бирү.

31. Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклаучы архив документларын муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга бирү.

32. Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклаучы архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү.

*Муниципаль хезмәтләр*

1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү.

2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую.

3. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аерым категория гражданнарны исәпкә кую.

4. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга торак урыны алу өчен субсидияләр бүлеп бирү.

5. Мәҗбүри күченүчеләргә торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификаты бирү.

6. Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруга рөхсәт бирү.

7. Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү.

8. Социаль наем шартнамәсе нигезендә гражданга муниципаль милектә булган торак урыны бирү.

9. Билгеләнгән тәртиптә муниципаль торак фондының торак урыннарын - яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану.

10. Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү.

11. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү.

12. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү.

13. Торак пунктта гамәлдәге җир кишәрлеген урнаштыру схемасын килештерү.

14. Җир кишәрлеген сайлау актын килештерү.

15. Биналар һәм корылмалар төзү өчен җир эшләре башкаруга ордер бирү.

16. Реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәт бирү.

17. Тәмамланмаган төзелеш объектын файдалануга рөхсәт бирү

18. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын эшләү һәм бирү.

19. Капиталь төзелеш объектына (шул исәптән тәмамланмаган төзелеш объектына) почта адресы бирү.

20. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон төзүне килештерү.

21. Инженерлык челтәрләренең һәм коммуникацияләрнең трассалары схемасын килештерү.

22. Агачлар һәм куаклар кисүгә, ябалдашларын кисүгә яки аларны утыртуга рөхсәт бирү.

23. Муниципаль берәмлек чикләрендәге җирле әһәмияттәге юллар буенча тулысынча яки өлешчә уза торган маршрутларда авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү.

24. Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү.

25. Муниципаль мөлкәтне (төзелешләрне, корылмаларны) муниципаль учреждениегә оператив идарә (түләүсез файдалану яки хуҗалык алып бару) хокукында рәсмиләштерү (беркетү).

26. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген муниципаль учреждениегә даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга бирү.

27. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү .

28. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бушлай милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

29. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бушлай вакытлы файдалануга бирү.

30. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

31. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

32. Җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылмаларның милекчеләренә милеккә яки арендага анда урнашкан җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

33. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган торгларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

34. Аукцион формасында уздырыла торган торгларда җир кишәрлеген сату юлы белән милеккә тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

35. Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

36. Муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

37. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына үзләренең эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

38. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

39. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга милеккә (арендага) бакчачылык алып бару өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү

40. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

41. Шәхси яисә муниципаль милектә булган җир кишәрлеген (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

42. Җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану яки гомерлек мирас итеп җир кишәрлегеннән файдалану хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

43. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

44. Муниципаль мөлкәт реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

45. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

46. Җир кишәрлекләре бирү хокукына ия булган затларны исәпкә кую буенча түләүсез муниципаль хезмәт күрсәтү.

47. Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

48. Муниципаль казнаны тәшкил иткән мөлкәтне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

49. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

50. Муниципаль мөлкәт реестрына керүче муниципаль мөлкәтне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

51. Муниципаль милекне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

52. Торглар үткәрмичә генә муниципаль берәмлек мөлкәтен бушлай файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

53. Мондый шартнамә төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалану шартнамәсе төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

54. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

55. Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү.

56. Җир кишәрлегенә белешмә бирү, йорт биләмәсенә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтәләр бирү.

57. Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф учреждениеләренә (балалар бакчалары) кабул итү һәм юлламалар бирү өчен чираттагылар исемлегенә кертү.

58. Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләрен бирү

59. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга архив документларын бирү.

60. Архив документларының урнашу мәсьәләләре буенча консультация бирү.

61. Ликвидацияләнгән оешмаларның шәхси составы буенча муниципаль архивка саклауга документлар кабул итү.

62. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау.